СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2020 елның 12 ноябре № 3/7

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 3 июнендәге 45/15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**10 пунктны** түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Комиссия составына конкурс үткәрүче җирле үзидарә органы вәкилләре, шул исәптән кадрлар хезмәте хезмәткәре, юридик хезмәт хезмәткәре, башка кызыксынган оешмалар вәкилләре кертелә.»;

**17 пунктта** «белешмәләре» сүзеннән соң «, хезмәт килешүе проектын» сүзләрен өстәргә;

**18 пунктның 9 абзацын** яңа түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ күчермәсе;».

2. Әлеге карар басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы,Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров